**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 11 май № 275

г. Казань

Лизинг һәм идарә компанияләрен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъектлары сыйфатында сайлап алу тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 ел, 24 июль, ФЗ-209 нчы Федераль законның 10 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасын формалаштыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Лизинг һәм идарә компанияләрен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъектлары сыйфатында сайлап алу тәртибен (карарга теркәлә) расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\275.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 11 май, 275 нче карары белән расланды

**Лизинг һәм идарә компанияләрен**
**Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъектлары сыйфатында сайлап алу тәртибе**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасының түбәндәге төп чараларын тормышка ашыру өчен шартлар булдыру максатларында, Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы (алга таба – финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы) субъектлары сыйфатында лизинг һәм идарә компанияләрен сайлап алуны үткәрү процедурасын билгели:

җиһазлар лизингын үстерү;

кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны), шул исәптән монопрофильле муниципаль берәмлекләрнең, тормышка ашыру кысаларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү;

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмаларга ярдәм итүнең гарантияле механизмнарын үстерү.

1.2. Әлеге Тәртиптә түбәндәге төп төшенчәләр файдаланыла:

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары – «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 ел, 24 июль, ФЗ-209 нчы Федераль законда билгеләнгән шартлар нигезендә кече предприятиеләргә, шул исәптән микропредприятиеләргә, һәм урта предприятиеләргә кертелгән хуҗалык итүче субъектлар (юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр);

финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъектлары – Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын) тормышка ашыру максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтүче оешмалар;

вәкаләтле орган – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы;

Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге – Татарстан Республикасының кече

һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру өлкәсендә функцияләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

идарә компаниясе – Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән һәм кыйммәтле кәгазьләр, хокуклар, таныкланган документар булмаган кыйммәтле кәгазьләр, махсус хокуклар һәм башка мөлкәт, шул исәптән «Инвестиция фондлары турында» 2001 ел, 29 ноябрь, ФЗ-156 нчы Федераль закон нигезендә инвестиция фондлары, пай инвестиция фондлары һәм дәүләткә карамаган пенсия фондлары белән ышанычлы идарә итүне гамәлгә ашыра торган акционерлык җәмгыяте яки җаваплылыгы чикләнгән (өстәмә җаваплылыгы булган) җәмгыять, шулай ук венчур инвестицияләре җәлеп итү һәм урнаштыру тәҗрибәсе һәм күнекмәләре булган юридик зат;

лизинг компаниясе – «Финанс арендасы (лизинг) турында» 1998 ел, 29 октябрь, ФЗ-164 нче Федераль закон һәм үзенең гамәлгә кую документлары нигезендә лизинг бирүче функцияләрен башкаручы коммерциячел оешма;

сайлап алу – идарә яки лизинг компаниясен финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъекты итеп тану процедурасы;

комиссия – сайлап алуны үткәрү өчен вәкаләтле орган тарафыннан төзелгән коллегиаль орган;

гариза бирүче – сайлап алуда катнашу өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәгенә заявка тапшырган идарә яки лизинг компаниясе;

сайлап алуда катнашу өчен заявка (алга таба – заявка) – сайлап алуда катнашу өчен кирәк булган, әлеге Тәртип таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән документлар.

1.3. Лизинг һәм идарә компанияләренә финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъектлары сыйфатында сайлап алуның төп принциплары булып ирекле, түләүсез һәм ачык булу тора.

## 2. Гариза бирүчеләргә таләпләр

2.1. Гомуми таләпләр (критерийлар):

оешма Татарстан Республикасында теркәлгән яки аның анда структур бүлекчәсе була һәм заявканы тапшыру вакытында үзенең эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә кимендә өч ел дәвамында гамәлгә ашыра;

оешма тарафыннан финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъекты сыйфатында үсеш стратегиясе (программасы) эшләнгән, һәм ул кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен финанс хезмәтләре күрсәтүне күздә тота;

оешманың салым йөкләмәләре, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына һәм бюджеттан тыш фондларга башка мәҗбүри түләүләр буенча, шулай ук кредит оешмаларына бурычлар буенча вакыты чыккан бурычлары булмый;

заявканы тапшырган көнгә кадәр килгән өч ел эчендә оешмага карата

акчасызлык (банкротлык) процедуралары куллану фактлары, шул исәптән күзәтү, финанс ягыннан сәламәтләндерү, тышкы идарә, конкурс җитештерүе булмый;

оешмага карата аның эшчәнлеген туктатып тору, үзгәртеп оештыру яки ябу турында карар булмый;

заявканы тапшырган елга кадәр килгән ел өчен гариза бирүченең бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы дөреслеге турында аудиторлык оешмасының, индивидуаль аудиторның билгеләнгән формада белдерелгән фикерен үз эченә алган уңай аудиторлык бәяләмәсе була.

2.2. Идарә компанияләре өчен таләпләр (критерийлар):

оешманың үз акчасы кимендә 20 млн.сум тәшкил итә;

оешманың үз акчасы һәм идарәдә булган активлар чагыштырмасы кимендә 10 процент тәшкил итә;

оешма тарафыннан кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлегенә акча инвестицияләү мөмкинлеге каралган эчке норматив документлар эшләнгән була.

2.3. Лизинг компанияләре өчен таләпләр (критерийлар):

финанс арендасына (лизинг) мөлкәт бирү эшчәнлеге оешманың гамәлгә кую документларында каралган һәм аның төп эшчәнлек төре булып тора;

оешманың актив операцияләре портфеленең кимендә 80 проценты эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра торган оешмалар белән төзегән шартнамәләр һәм алыш-бирешләр буенча формалаштырылган була;

оешма кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс арендасына (лизинг) мөлкәт бирү хезмәтләрен күрсәтә;

оешма тарафыннан расланган лизинг алучыларның финанс хәлен бәяләү методикасы була;

оешманың актив операцияләре портфеле диверсификацияләнгән, ягъни лизинг алучыларның теләсә кайсы белән төзелгән барлык лизинг шартнамәләре буенча калган бурыч портфель буенча гомуми калган бурычның 35 процентыннан артмый;

төзелгән лизинг шартнамәләре буенча лизинг алучыларның вакыты чыккан бурычлары дәрәҗәсе соңгы хисап датасына гомуми калган бурычларның 5 процентыннан артмый;

оешма тарафыннан агымдагы ел башына кимендә 50 млрд.сум күләмендә үз акчасы (капиталы) булган яисә Россия Федерациясе Үзәк банкының яки Россия Федерациясенең туры яки турыдан-туры булмаган контролендә булган кредит оешмасы белән хезмәттәшлек турында килешү төзелгән була.

## 3. Сайлап алуны үткәрү механизмы

3.1. Гариза бирүче Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәгенә заявка тапшыра, һәм ул үз эченә түбәндәге документларны ала:

вәкаләтле орган раслаган форма буенча гариза;

гариза бирүченең гамәлгә кую документлары күчермәләре;

гариза бирүчене дәүләт теркәвенә алу турында шаһәдатнамә күчермәсе яисә юридик затларның бердәм дәүләт реестрына язма кәгазе;

гариза бирүчене салым исәбенә алу турында шаһәдатнамә күчермәсе;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча гариза бирүченең үтәлмәгән бурычы булмавын раслый торган һәм заявка тапшырган айга кадәр килгән ай ахырына билгеләнгән тәртиптә таныкланган салым органы белешмәсе;

заявканы тапшырган елга кадәр килгән ел өчен гариза бирүченең бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы дөреслеге турында аудиторлык оешмасының, индивидуаль аудиторның билгеләнгән формада белдерелгән фикерен үз эченә алган аудиторлык бәяләмәсе күчермәсе;

гариза бирүче раслаган финанс ярдәменә дәгъва иткән кече яки урта эшмәкәрлек субъектының финанс хәлен бәяләү методикасы күчермәсе;

заявканы тапшырган көнгә кадәр килгән өч ел эчендә гариза бирүчегә карата акчасызлык (банкротлык) процедуралары куллану фактлары, шул исәптән күзәтү, финанс ягыннан тергезелү, тышкы идарә, конкурс җитештерүе булмавын, шулай ук гариза бирүчегә карата аның эшчәнлеген туктатып тору, үзгәртеп оештыру яки ябу турында карар булмавын раслый торган гариза бирүче җитәкчесе имзасы белән фирма бланкында хат;

оешма тарафыннан агымдагы ел башына кимендә 50 млрд.сум күләмендә үз акчасы (капиталы) булган яисә Россия Федерациясе Үзәк банкының яки Россия Федерациясенең туры яки турыдан-туры булмаган контролендә булган кредит оешмасы белән хезмәттәшлек турында килешү күчермәсе (лизинг компанияләре өчен);

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлегенә акча инвестицияләү мөмкинлеге каралган эчке норматив документлар күчермәләре (идарә компанияләре өчен) – ябык пай инвестиция фонды белән ышанычлы идарә итү кагыйдәләре;

финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъекты буларак гариза бирүченең үсеш стратегиясе (программасы), ул үз эченә Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү өчен уңай шартлар тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны кимендә өч ел дәвамында гамәлгә ашырыла торган һәм (яки) гамәлгә ашырырга планлаштырыла торган комплексы тасвирламасын, шулай ук әлеге чараларның нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен ала, шул исәптән:

гариза бирүченең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү максатларында бирелә торган финанс продуктлары һәм күрсәтелә торган хезмәтләре тасвирламасы, әлеге финанс продуктларын һәм хезмәтләрне сорауны бәяләү;

гариза бирүченең финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъекты буларак үсеш стратегиясен (программасын) тормышка ашыруы өчен финанс чыганакларын билгеләү;

гариза бирүче эшчәнлеге аларны булдырырга мөмкинлек бирәчәк яңа эш урыннары санын, шулай ук барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларга бүленгән салымнарның планлаштырылган күләмен (салымнар төрләре һәм бюджетлар дәрәҗәләре буенча) күрсәтеп (үсеш еллары буенча бүлеп), гариза бирүченең финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъекты буларак үсеш стратегиясен (программасын) тормышка ашыруы нәтиҗәлелеге күрсәткечләре;

булган һәм булырга мөмкин куркынычларны бәяләү.

Әлеге пунктта күрсәтелгән документларның күчермәләре гариза бирүче җитәкчесе имзасы һәм гариза бирүче мөһере (булганда) белән раслана.

3.2. Заявкалар 1 февральдән 30 ноябрьгә кадәрге чорда (30 ноябрьне дә кертеп) кабул ителә. Заявка кергән көн булып аны электрон теркәү журналында теркәгән көн санала, теркәү аны алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә гамәлгә ашырыла. Агымдагы айда кертелгән заявкалар комиссия тарафыннан заявканы тапшыру аеннан соң килә торган ай ахырына кадәр карап тикшерелә.

3.3. Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге заявка кертелгән көннән соң календарь көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә заявканы әлеге Тәртипнең 3.1 нче пунктында куелган таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Заявканың бу Тәртипнең 3.1 нче пункты таләпләренә туры килмәве гариза бирүчене сайлап алуга кертүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

3.4. Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге җитәкчесе тикшерү нәтиҗәләре буенча гариза бирүчене сайлап алуга кертү турында яки кертүдән баш тарту хакында мәгълүматны үз эченә алган бәяләмәгә кул куя.

Гариза бирүчене сайлап алуга кертү турында яки кертүдән баш тарту хакында мәгълүмат вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайтында заявка Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәгенә кертелгән көннән соң календарь көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә урнаштырыла.

3.5. Вәкаләтле орган комиссия утырышын үткәрү көне, вакыты һәм урыны турындагы мәгълүматны вәкаләтле органның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында утырышны үткәрү көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштыра.

3.6. Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге тарафыннан сайлап алуга кертелгән гариза бирүчеләрнең заявкалары комиссия утырышында гариза бирүче җитәкчесе яисә законнар буенча рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә гариза бирүче вәкиле катнашында карап тикшерелә.

Гариза бирүче җитәкчесе яки гариза гариза бирүче вәкиленең комиссия утырышына килмәве комиссиянең заявканы карап тикшерүенә комачауламый.

3.7. Комиссия утырышы, әгәр аның исемлек буенча составыннан кимендә яртысы катнашса, хокуклы була. Комиссия составы вәкаләтле орган тарафыннан раслана. Комиссия үз эшен оештыру тәртибен мөстәкыйль рәвештә билгели.

Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән комиссия утырышында катнашучы әгъзалары саныннан тавышларның гади күпчелеге нигезендә кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта карар гариза бирүче файдасына кабул ителә.

Сайлап алу нәтиҗәләрендә шәхси мәнфәгатьләре булган (шул исәптән әлеге заявкаларны тапшырган оешмалар штатында исәпләнгән) яисә сайлап алуда катнашучылар аларга йогынты ясарга мөмкин булган затлар (шул исәптән гариза бирүчеләрнең катнашучылары (акционерлары), аларның идарә органнары әгъзала-

ры, гариза бирүчеләрнең кредиторлары булган физик затлар) комиссия әгъзалары була алмый.

3.8. Заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларны кабул итә:

гариза бирүчене финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъекты итеп тану һәм вәкаләтле орган раслаган форма буенча шаһәдатнамә бирү турында. Шаһәдатнамә, комиссия утырышы үткәрелгән көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, өч елга бирелә;

гариза бирүчене финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъекты итеп танудан баш тарту хакында.

3.9. Гариза бирүчене финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъекты итеп танудан баш тарту өчен нигез булып гариза бирүченең әлеге Тәртипнең 2 бүлегендә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве тора.

3.10. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аны комиссия секретаре алып бара. Беркетмә комиссия рәисе тарафыннан комиссия утырышын үткәргән көннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча раслана. Беркетмә вәкаләтле органның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында аны раслаган көннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

3.11. Финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъекты итеп танудан баш тартылган гариза бирүче бу Тәртип нигезендә яңа заявка белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.12. Финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъектларының әлеге Тәртип таләпләренә туры килүен раслау ел саен, шаһәдатнамә гамәлдә булган чорда, әлеге Тәртипнең 4.2 һәм 4.3 нче пунктларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

## 4. Финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъектлары реестрын алып бару

4.1. Вәкаләтле орган финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъектлары реестрын вәкаләтле орган раслаган форма буенча формалаштыра һәм ел саен, 30ына кадәр актуальләштерә һәм үзенең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра.

4.2. Финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъектлары ел саен, 30 мартка кадәр, вәкаләтле орган раслаган форма буенча үзләренең эшчәнлек нәтиҗәләре турында мәгълүматны, шулай ук, аларга үзгәрешләр (өстәмәләр) кертелгән очракта, бу Тәртипнең 3.1 нче пунктында каралган документларны вәкаләтле органга тапшыра.

4.3. Вәкаләтле орган, финанс ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъектына бирелгән шаһәдатнамәне әлеге Тәртипнең 2 бүлегендә каралган таләпләргә туры килмәвен билгеләгән яки бу Тәртипнең 4.2 нче пунктында күрсәтелгән вакыт эчендә үзенең эшчәнлек нәтиҗәләре турында мәгълүмат тапшырмаган көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, аны үзенең боерыгы белән гамәлдән чыгара.

## 5. Сайлап алуда катнашучы затларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл

кылмауларына) шикаять бирү тәртибе

5.1. Гариза бирүче Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәгенең, вәкаләтле органның, комиссия һәм аларның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

---